СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-44; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

«28» июль, 2017 ел — № 2-22

Олыяз авыл җирлеге Советының
2016 елның 3 октябрендәге
«Җир салымы турында» 2-15 номерлы
карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү хакында

2017 елның 21 июнендәге 02-08-02-17 номерлы прокурор протесты, Салым кодексының 391 статьясының 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Олыяз авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында» 2-15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым базасын салым түләми торган суммага киметү хокукын раслаучы документлар Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезендә салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла.».

2. Әлеге карарны «Нократ» («Вятка») район газетасында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында http://madysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге Советы рәисе — И.Я.Хаев